***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

# БИРЕМНӘРЕ

(2024-2025 нче уку елы)

**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**м**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Көчең белән мактанма, эшең белән мактан.* (Мәкаль)
а) 1
ә) 2
б) 3
в) 4

2. Җөмләдәге ачык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Берәүнең буе кыска, берәүнең уе кыска.* (Мәкаль)
а) 5
ә) 7
б) 8
в) 10

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***усак яфрагы***
а) кечкенә кеше
ә) тиктормас, кыбырсык кеше
б) яшь, тәҗрибәсез кеше
в) тырыш, эшчән кеше

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
а) шәһәр
ә) хат
б) вәгъдә
в) авыл

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) уен(көлке)
ә) тере(көмеш)
б) кара(бөрлегән)
в) каз(үрдәк)

6. Вакыт рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) сишәмбе
ә) шактый
б) кич
в) бүген

7. Затланышсыз фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) боерык фигыль
ә) шарт фигыль
б) исем фигыль
в) хикәя фигыль

8. Сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) диңгез
ә) тирән диңгез
б) диңгез, күл
в) Кара диңгез

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Читлеккә* ***өйрәнгән*** *кош ректә башын югалтыр*. (Мәкаль)

а) ия
ә) хәбәр
б) рәвеш хәле
в) аергыч

10. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сукыр тычканга карт мәче дә арыслан булып тоела*. (Мәкаль)

а) сукыр
ә) мәче
б) булып
в) тоела

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

_____________ килешендәге I һәм II зат алмашлыклары _____________ гармониясенә буйсынмыйлар. Язылышлары бердәй, әмма әйтелешләрендә аерма булган сүзләр _____________ дип атала. Бер тамырдан булган сүзләр – _____________ сүзләр. _____________ предметның яисә затның төрле билгеләрен белдерә. Саналмыш һәрвакыт _____________ санда килә. Җөмләдәге сүзләр арасында тезүле һәм _____________ бәйләнеш була. _____________ хәле беркайчан да аерымланмый.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Сүзләрне дөрес итеп урнаштырып, ике мәкаль языгыз. **(4 балл)**

*ит, вак, белән, кире, карчыга, йөри, балык, авызыннан, чыкмый, көтүе*

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

На уроке ученики читают вслух, пишут, рассказывают, много говорят по-татарски. Иногда они отвечают правильно, иногда неправильно. Когда дети говорят неправильно, учительница исправляет их ошибки.

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ТАҢ

Таң ата, дип ишеткән бар
Әбидән дә, бабайдан да.
Ә үземнең таң атканын
Күргәнем юк беркайчан да.
Бүген менә **шуңа күрә**
Уяндым да караңгыдан,

“Таң ничек ата соң?” – диеп
Карап торам тәрәзәдән.
Башта үзем куркып куйдым:
Караңгыда күрә алмам.
Хәзер тышта якты инде,
Таң атканын күрми калмам.

*(Равил Фәйзуллин)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)** _____________________________________________

2.2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз, басымнарын билгеләгез **(3 балл)** _____________________________________________

2.3. Иртүк торуны белдергән фразеологизмны искә төшереп языгыз. **(2 балл)**

__________________________________________________________________

2.4. Кушма сүзләрне күчереп языгыз. **(1 балл)** __________________________

2.5. ***Якты*** сыйфатын дәрәҗәләр белән төрләндереп языгыз. **(1 балл)**

__________________________________________________________________

2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төрен языгыз. **(2 балл)**

__________________________________________________________________

3. Шигырьдәге геройны тасвирлап, 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________